РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 17 » 02 2022 № 49

Аксубаево

«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметлары булган муниципаль контрактларны банк белән тәэмин итү очракларын билгеләү турында» 2016 ел, 23 декабрь, 715 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларны банк белән тәэмин итү турында» 2014 ел, 20 сентябрь, 963 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметлары булган муниципаль контрактларны банк белән тәэмин итү очракларын билгеләү турында» 2016 ел, 23 декабрь, 715 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. контрактны үтәү кысаларында исәп-хисап мониторингы банк тарафыннан җәлеп ителгән, заказ бирүче (подрядчы, башкаручы) яки заказчы тарафыннан контрактны үтәү кысаларында банк белән тәэмин итүгә карата 200 млн. сумнан да ким булмаган күләмдә акча каралган;

1.2. контрактны тәэмин итү максатыннан тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) яки заказчы тарафыннан хезмәт күрсәтүләрне җәлеп итүне күздә тоткан банк контракт шартларына, кабул ителә торган товарларның, эшләрнең (аларның нәтиҗәләренең), хезмәт күрсәтүләрнең контракт шартларына туры килүен тәэмин итү максатларында, 500 млн. сумнан да ким булмаган күләмдә банк белән тәэмин итү күздә тотыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев